КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 20 сентябрь г.Казань № 817

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Мелиорация чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Җиләк һәм җимеш бирә торган күпьеллык куак үсентеләрен утыртуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Сугару һәм киптерү системаларын, шулай ук аерым урнашкан гидротехник корылмаларны төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау проектларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Эрозиягә каршы һәм кырларны саклау өчен урман утыртмаларын утыртуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Балык үрчетү хуҗалыклары тарафыннан мәрсин балыгы төрләренең товар балыгын һәм товар уылдыгын сатуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Азык сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен сөт бирә торган кәҗәләр үрчетүне һәм (яисә) асрауны гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Социаль икмәк пешерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен икмәк пешерү предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 ел, 3 июль, 534 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карары белән расланган Үсемлекчелекне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар чыгымнарының бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2021 ел, 20 август, 750 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 ел, 6 октябрь, 951 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2021 ел, 17 декабрь, 1245 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 15 март, 239 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына

үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 13 июль, 673 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 27 сентябрь, 1038 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 11 февраль, 133 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 22 июнь, 734 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 8 сентябрь, 1114 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 ел, 21 март, 171 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 ел, 15 июнь, 429 нчы.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин